**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы**

**Иске Салман авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

2018 елның 24 августы 21 №

**«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын гамәлгә ашыру максатларында Иске Салман авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы муниципаль районының Иске Салман авыл җирлегенең торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне, кушымта нигезендә, расларга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
3. Аның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Совет рәисе,
Иске Салман авыл җирлеге башлыгы Ф.И.Җәләлетдинов

СОВЕТ СТАРОСАЛМАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ